**«Исәнме, мәктәп!» сериясе**

# Бал корты һәм Шөпшә

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2008

УДК 821.512.145-3-93
ББК 84(2Рос=Тат)-4
Б20

Серия авторы, автор-төзүчесе һәм мөхәррире **Талия ШАКИРОВА**

Рәссамнары: **Алла АЙСЕНА, Валерий ФОМИН**

Бал корты һәм Шөпшә: эчтәлек сөйләргә өйрәнәбез / сер. авт., авт.-төз. һәм мөх. Т.Р.Шакирова; рәс.: А.Айсена, В.Фомин. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. — 72 б.: рәс. б-н. — 5000 д. — ISBN 978-5-298-01713-8

«Исәнме, мәктәп!» сериясенең әлеге дүртенче китабы «Балалар бакчасында тәрбия һәм белем бирү программасы»на нигезләнеп эшләнде.

УДК 821.512.145-3-93
ББК 84(2Рос=Тат)-4

ISBN 978-5-298-01713-8
© Татарстан китап нәшрияты, 2008
© Шакирова Т.Р., төзү, 2008

# Хөрмәтле эти-әниләр һәм тәрбиячеләр!

Сез «Исәнме, мәктәп!» сериясенең дүртенче китабын кулыгызга алдыгыз. Ул «Бал корты һәм Шөпшә» дип атала. Китап әсәрнең эчтәлеген сөйләргә өйрәтә.

Баланың сөйләм теле үссен өчен, әсәрне укып чыгу гына җитми. Әгәр балагыз матур, төзек җөмләләр белән бәйләнешле итеп сөйләргә өйрәнсен дисәгез, аңа булышыгыз. Бу эштә сезгә «Бал корты һәм Шөпшә» ярдәмгә килер. Ул — укуга һәм эчтәлек сөйләүгә корылган текстлар җыелмасы гына түгел, үзенчәлекле китап.

Эчтәлек сөйләү ул — әсәрне яттан сөйләү түгел. Балагыз текстның сүзен сүзгә исендә калдырырга тырышмасын. Киресенчә, мәгънәләре якын сүзләрне бер-берсе белән алмаштырып, җөмләләрне үзе төзесен.

Әсәрнең эчтәлеген сөйләргә өйрәтүнең мөһим элементы — сорауларга җавап бирү. Бу вакытта бала вакыйгаларның эзлеклелеген исендә калдыра; геройларның эш-гамәлләренә анализ ясарга өйрәнә, үз карашын белдерә. Бу максаттан китапта башта текстларга сораулар тәкъдим ителә. Алга таба бала төрле оригиналь алымнар, мавыктыргыч биремнәр, уеннар, башваткычлар ярдәмендә сюжет элементларын хәтерендә кабат яңарта. Геройларга мөнәсәбәтле бирелгән табышмакларның җавапларын әйтә, мәкаль-әйтемнәрдә яшеренгән фикерне аңлата. Шуның белән бергә проблемалы уен-биремнәрне мөстәкыйль үтәргә өйрәнә, сөйләм күнекмәсе ала. Ә бу — баланы мәктәпкә әзерләүнең иң нәтиҗәле чарасы.

Сез бу китапны бергәләп укыгыз, өйрәнегез, шатланыгыз. Ә без, Татарстан китап нәшрияты хезмәткәрләре, балагызның сәламәт рухлы, белемле кешеләр булып үсүенә ышанып калабыз.

*Талия Шакирова*

## Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар

*(Әкият)*

Күз күреме җитмәслек, очына-кырыена чыгып бетмәслек бик зур бер болында күкрәп үләннәр үскәннәр. Чалгы белән чабарлык булып өлгергәннәр. Төрле төстәге матур чәчәкләр анда хуш исләр таратканнар. Кош-кортлар үзләренең матур сайраулары белән болынны яңгыратканнар.

Менә шундый матур болында ат көтүе йөргән. Дугадай муенлы, стакан тояклы аргамаклар болын үләнен ашаганнар. Туйганчы салкын чишмә суын эчкәннәр.

Бу атларның көтүчеләре булмаган. Бары тик үз араларыннан иң сылу, йөгерек, иң җитез Җирән Кашка гына көтүче хезмәтен үти икән. Ул, муенындагы кыңгыравын шалтыратып, башкаларны үз артыннан ияртә, барысын бергә туплап йөртә икән.

Җирән Кашка беркөнне бик арыган, кичен аның йокысы калган булган. Ул ятып бераз хәл җыярга, йоклап алырга уйлаган. Иптәшләренең барысын бергә җыйнаган да әйткән:

— Аерылсагыз — айга җитмәссез, бүленсәгез — бүген бетәрсез, бергә йөрсәгез — рәхәт көн итәрсез, — дигән.

Атлар башта гел бергә йөргәннәр. Кичкә таба берничәсе бик начар иткән: көтүдән аерылып киткән. Алар Җирән Кашканың сүзләрен онытканнар. Аның файдалы киңәшен тотмаганнар.

Аерылып киткәннәре килбәтсез зур бер аюга очраганнар, куркуларыннан һушсыз була язганнар, бик тиз кайту юлына борылганнар. Ләкин аю алар артыннан калмаган. Әй куган, әй куган, хәер, тота алмаган. Әй йөгергәннәр, әй йөгергәннәр атлар, юлларында тау очраган — йөгереп менгәннәр, урман очраган — ерып чыкканнар, чокырдан сикерергә уйлаганнар — булдыра алмаганнар. Тирән чокыр эченә егылганнар, аякларын сындырганнар.

Тагын өчесе көтүдән бүленеп киткән булган. Күп үтмәгән, алар да Җирән Кашканың туры сүзләрен исләренә төшергәннәр, үзләренең бүленеп китүләренә үкенгәннәр, ләкин инде соң булган. Каршыларына тешләрен шыкырдатып, күзләрен акайтып бер соры бүре килеп чыккан. Алар, бу явыз

дошманны күргәч, каушап калганнар, үзләрен-үзләре белештерми, ярсып, кайсы кая таралганнар. Бүре шунда ук бер атның бугазына ябышкан, буып алган, егып та салган. Калганнары качып котылганнар. Җирән Кашка муенындагы кыңгыравының матур шалтыравын ишеткәннәр һәм туп-туры шунда карап киткәннәр.

Барысы да Җирән Кашкага үз башларыннан үткән хәлләрне сөйләп биргәннәр, аның туры сүзен тотмауларына бик үкенгәннәр. Ә Җирән Кашка башын чайкаган, кыңгыравын көчле итеп бер шалтыраткан — көтү бергә җыелган, тагын бер шалтыраткан да сөйләргә тотынган:

— Күрдегезме сүземнең дөреслеген: аерылганнар аюдан өркеп һәлак булдылар, бүленгәннәр бүрегә очрадылар, — дигән дә кыңгыравын өченче мәртәбә шалтыраткан һәм барлык аргамакларын болынга җыйган.

*Абдулла Алиш*

# Сорауларга җавап бир

**1.** Болында нәрсә көтүе йөргән?
**2.** Көтүче хезмәтен кайсы ат
үтәгән?
**3.** Беркөнне Җирән Кашка иптәшләрен бергә җыйган да болай дигән:
— Аерылсагыз — айга җитмәссез, бүленсәгез — бүген бетәрсез, бергә йөрсәгез — рәхәт көн итәрсез.
Җирән Кашка бу сүзләре белән атларга нәрсә әйтергә теләгән?
**4.** Атлар Җирән Кашканың киңәшен тотканнармы?
**5.** Аерылып киткән атларга нәрсәләр очраган?
**6.** Алар аю белән бүредән ничек котылганнар?
**7.** Атлар Җирән Кашканың киңәшен тыңламаганнары өчен үкенгәннәрме? Тыңлаган булсалар, алар бу бәлаләргә юлыккан булырлар идеме? Димәк, без, кешеләр дә, ничек яшәргә тиеш?
**8.** Син бу сүзләр белән килешәсеңме? Ни өчен?
**9.** Дуслык, бердәмлек турында тагын нинди мәкаль-әйтемнәр беләсең?
**10.** Син үзең әкияткә нинди исем куяр идең?

# Җөмләләрне әйтеп бетер

Менә шундый матур болында ат көтүе ... .

Аю атлар артыннан әй куган, әй ... , әмма ... ... .

Каршыларына тешләрен шыкырдатып, күзләрен акайтып, бер соры бүре ... ... .

Барысы да Җирән Кашкага үз башларыннан үткән хәлләрне ... .

# Табышмакларның җавапларын тап

Сабан туенда узыша,
Бар эшемә булыша.
Утырдым исә биленә,
Илтә кирәк җиремә.
Килә бер батыр атлап,
Аягын баса лап-лап.
Урманда йөри,
Умартадан бал көри.
Сорыдыр төсе,
Үткендер теше.
Урманда йөри,
Бозаулар эзли.

**Ай белән Кояш**

*(Татар халык әкияте)*

Ай белән Кояш элек заманда гел бер җирдә генә тормакчы булганнар. Менә алар, бөтен кошларны җыеп, шул турыда җыелыш ясаганнар. Кошлар, - боларның бер җирдә торуларына риза булып, шуңар кул куйганнар.

Болар арасында бары бер генә кош — Ярканат кына кул куймыйча калган, ди. Бүтән кошлар Ярканаттан сораганнар:

— Барлык кошлар кул куйганда, нилектән син генә кул куймадың? — дигәннәр.

— Кулны мин, — дигән Ярканат, — шул сәбәпле куймадым, Кояш белән Ай бер җирдә генә торсалар, җил бер генә яктан исәр, агачлар кәкре булып үсәр, игеннәр дә Кояш төшкән җирдә генә үсәр. Кояш төшмәгән җирдә үсмәс, — дигән.

Шуннан соң бүтән кошлар әйткәннәр:

— Дөрес әйтә, Кояш төшмәгән җирдә иген үсми, — дигәннәр.

Ай белән Кояшның икесенә дә бер җирдә генә тормаска, әйләнеп йөрергә, дип карар чыгарганнар, ди.

Шуннан соң Кояш әйткән Ярканатка:

— Мин сине үземнең яктылыгымда йөртмәячәкмен, — дигән.

Шунлыктан Ярканат көн яктысына чыгып йөри алмый икән.

Ай Ярканатка каршы сүз әйтмәгән, шуңа күрә ул ай яктысында бик әйбәт йөри, ди.

# Сорауларга җавап бир

**1.** Ай белән Кояш нишләмәкче булганнар?

**2.** Кошлар аның белән килешкәннәрме?

**3.** Ярканат ни өчен кул куймаган?

**4.** Ә син ничек уйлыйсың, Ярканат дөрес әйткәнме? Кояш төшмәгән җирдә үсемлекләр, иген үсәме? Иген үсмәсә, нәрсә булыр иде?

**5.** Мәкальдәге сүзләрне Ярканатка бәйләп аңлат.

**6.** Ярканат ни өчен кояш яктысына чыгып йөри алмый башлаган?

# Күпнокталар урынына сүзләр куеп әйт

... белән ... элек заманда гел бер җирдә генә тормакчы булганнар.

... кул куймыйча калган.

... әйткәннәр:

— Дөрес әйтә, Кояш төшмәгән җирдә иген үсми.

### Ак песи

Төзүче абыйлар һәм апалар бик матур биш катлы йорт җиткерделәр. Шул матур йортның беренче подъездына өч малай, өч кыз күчеп килде. Алар бик тиз танышып, дуслашып киттеләр. Кыш көннәрен дә, яз көннәрен дә, җәй көннәрен дә гел бергә уйнап үткәрделәр.

Менә көз җитте. Агач яфраклары саргайды. Яңгырлар ява башлады. Кошлар җылы якларга очып киттеләр.

Яңгырлы бер көндә Айдар балалар бакчасына бармады... Киенеп, урамга чыгып китте.

Урамда кояш юк иде. Һавадагы болытларны һәм җирдәге сары яфракларны куып, салкын җил генә исә иде. Айдар урамда кызык тапмады... Колаклары туңгач, өйләренә кереп китте.

Подъезд ишеген ачкан иде, кемдер нечкә тавыш белән:

— Мияу-у! — дип кычкырып куйды. Почмакта ап-ак песи утыра иде. Айдарны күргәч, тагын нечкә генә итеп: — Мияу-у! — дип куйды.

— Туңып беткәнсең бит. Әйдә безгә кербез, песикәй, мин сиңа сөт белән күмәч бирермен. Җылынырсың да, тамагың да туяр, — диде Айдар.

Ләкин песи урыныннан кузгалмады.

Айдар, тәлинкә белән җылы сөт һәм йомшак күмәч кисәге алып чыгып, аның алдына куйды. Песи юка кызыл теле белән челт-челт итеп сөт эчә

башлады. Аны бетергәч, күмәчне дә ашап куйды. Тамагы туйгач, ал аякларына башын куеп, күзләрен йомды да тәмле йокыга талды.

Айдар, аны тизрәк дусларына күрсәтү өчен, Галимнең, Рәзинә белән Рәзимәнең, Тимер белән Карачәчнең бакчадан кайтуларын көтә-көтә аптырап бетте. Кайтып керүләренә:

— Безгә песи килде! — дип сөенче алды.

Дуслары да песине бик яраттылар.

— Ур-ра! Ур-ра! — дип шатландылар.

Соңыннан, җыелышып утырып, аңа исем эзли башладылар.

*Газиз Мөхәммәтшин*

## Сорауларга җавап бир

**1.** Төзүчеләр нәрсә җиткерәләр?

**2.** Йортның беренче подъездына кемнәр күчеп килә?

**3.** Алар ничек яшиләр?

**4.** Айдар кая чыгып китә?

**5.** Көн нинди була? Көзге табигать турында сөйлә.

**6.** Өйгә кергәндә, Айдар нәрсә күрә?

**7.** Ул песигә нәрсә бирә?

**8.** Дуслары песине яраталармы?

**9.** Айдарны рәхимле, шәфкатьле дип әйтеп буламы? Ни өчен?

**10.** Ә син песигә нинди исем кушар идең?

**11.** Сезнең песиегез бармы? Булса, шул турыда сөйлә: исеме ничек, нинди төстә, нәрсә ашый һ.б.

**12.** Хикәяне үзең ничек дәвам итәр идең?

*Миһербанлы кеше — бәхетле кеше.*

Мәкаль

**13.** Син бу сүзләр белән килешәсеңме? Миһербанлы кеше ни өчен бәхетле була?

## Күпнокталар урынына сүзләр куеп әйт

— Әйдә безгә керәбез, песикәй, мин сиңа ... белән ... бирермен.

... юка кызыл теле белән челт-челт итеп сөт эчә башлады.

... дусларының бакчадан кайтуларын көтә-көтә аптырап бетте.

... , җыелышып утырып, аңа исем эзли башладылар.

### Бүләк кемгә?

*(Татар халык әкияте)*

Бервакыт Кояш елның дүрт фасылын — Көзне, Кышны, Язны һәм Җәйне — үзенә чакырып алган.

— Сезнең кайсыгыз матуррак, кайсыгыз эштә батыррак? Шуңа бүләк бирәм, — дигән.

Ә бүләк бик затлы икән — уч тутырып йолдыз бирергә уйлаган Кояш.

Сүзне Көз башлаган:

— Үзегез яхшы беләсез, мин бөтен басуларның уңышын җыйдым, бар дөньяны алтынга күмдем. Кошларны җылы якка озаттым, балаларны мәктәпкә җыйдым. Бүләк миңа тиеш!

— Әллә мин аз эшләдемме? — дип сикереп торган Яз. — Мин барлык карларны эреттем, басуларга иген чәчтем, кошларны чакырып кайтардым, агачларны яфрак ярдырдым, болыннарны чәчәккә күмдем. Арада иң матуры да, иң булдыклысы да мин! — дигән ул.

— Ай-яй, — дигән Җәй, — мине тыңлагыз әле, мин дөньяны яшеллеккә күмәм, чәчәкләр үстерәм, игеннәрне өлгертәм, җимешләрне пешерәм. Әллә мин иң матурыгыз түгелме?

— Артык күп түгел минем эш, — дигән Кыш, тыйнак кына. — Мин җирне ял иттерәм, киләсе уңыш өчен карлар ташыйм, дөньяны ап-акка буйыйм, балаларны чана, чаңгы шуарга чакырам. Мин дә ямьсез түгел. Минем чыршыларымны, кар бөртекләремне, мамык бәсләремне яраталар.

Кояш тыңлап-тыңлап торган да бүләкне берсенә дә бирә алмаган. Йолдызларны күккә сипкән. «Әнә барыгызга да!» — дигән.

Йолдызларны елның бер фасылы да үзенә ала алмаган. Алар һәрвакыт — яз да, җәй дә, көз дә, кыш та балкып яналар.

## Сорауларга җавап бир

**1.** Әкияттә сүз нәрсә турында бара?

**2.** Кояш дүрт ел фасылына нәрсә бүләк итәргә теле?

**3.** Көз нәрсә дип җавап бирә? Син Көзнең җавабы белән килешәсеңме? Ни өчен?

**4.** Көзнең «Бар дөньяны алтынга күмдем» җөмләсен ничек аңлыйсың? Җирне алтынга күмеп буламы? Бу җөмләне башкача ничек әйтер идең?

**5.** Ә Яз бүләк кемгә тиеш дип саный? Моны ничек аңлата?

**6.** Җәй аларның сүзләре белән килешәме?

**7.** Кыш бүләкне кемгә тәкъдим итә?

**8.** Кояш иң эшчән, иң матур ел фасылы дип кайсысын сайлый?

**9.** Кояш йолдызларны күккә сибеп дөрес эшләгәнме? Ни өчен, аңлат.

**10.** Ә син үзең елның кайсы фасылын яратасың?

## Табышмакларның җавапларын әйт

Берсе яшел келәм тукый,
Берсе сарыга мана.
Берсе ак мамыгын түши,
Ә берсе җыеп ала.

Һәр көн диярлек
Елап яшь коя.
Килгән кошларны
Көньякка куа.

Тәңкә карлар сипкән,
Җирне ап-ак иткән.
Чыршы, каен, имән
Кардан чикмән кигән.

Иң иртә ул күренә,
Менеп китә үренә.
Сокланамын эшенә —
Нур сибә бар кешегә.

Ай янында алтмыш күз,
Алтмышы да алтын күз.

Кара мыеклы җизнәм
Сагындырып килгән.

Кояш көлә,
кошлар сайрый,
Урманда җиләк пешә.
Бу күңелле, җылы вакыт
Кыш җиткәч искә төшә.

## Кояштагы тап
*(Әкият)*

Еракта, еракта, Каф тавының аръягында, кояш һәр көн йокларга кайта торган җирдә яшәгән, ди, бер малай. Малайның бары тик әнисе генә булган, ди. Малайның әнисе кояш белән бергә торган, кояш белән бергә яткан. Ул көннәр буе нидер чәчкән, нидер төзәткән, нидер яңарткан. Ә улы аңардан юри дә: «Әнием, син көннәр буе бил турайтмыйча ниләр эшлисең соң?» — дип сорамаган, гел уйнаган да уйнаган.

Менә көннәрдән бер көнне малайның әнисе, авырып, түшәккә егылган. Шунда ул урамда болытларга ук атып йөрүче улын чакырып керткән дә болай дигән:

— Улым, үзең күрәсең, хәлем кинәт начарланып китте. Хәтта суга барырга да өлгерми калдым. Ә минем бик-бик эчәсем килә. Иреннәрем кара көеп чыкты. Берәр чиләк су гына алып кайтчы, балам.

Малай, үзен кызыклы уеннан бүлдергән әнисенә канәгатьсезлек белән карап:

— Суны иртән тору белән алып кайтып куйсаң булмый идемени? — дигән.

— Иртүк алып кайтсам, көн буена җылынып бетәр дип уйладым. Син бит кичләрен, уеннан арып кайткач, салкын су эчәргә яратасың, — дигән малайның әнисе.

Малай бик авырлык белән генә суга барырга ризалык белдергән.

— Улым, — дигән әнисе аңар, — суны теге Көймә тавы артындагы чишмәдән ал. Аның суы тәмле дә, салкын да, шифалы да.

Малай, чиләген күтәреп, урамга чыккан. Кулын кашына куеп, Көймә тавына таба караган. Көймә тавы бик-бик еракта, зәңгәр офыклар артында булып күренгән аңа. Җитмәсә, кояшы өтеп алырдай итеп кыздыра икән.

«Мондый кызуда шултиклем еракка барып йөргәнче, суны менә шушы якындагы чишмәдән алсам да ярар әле», — дип уйлаган малай һәм, чиләген бер читкә куеп, өр-яңадан уйнарга тотынган. Үзенең дә бик каты эчәсе килгәч кенә, суга барырга кирәклеге исенә төшкән.

Менә ул бермәлне тирләп-пешеп судан кайтып кергән. Әнисе, аның чәчләреннән сыйпап: «Рәхмәт, улым, бик зур рәхмәт», — дигән. Һәм, йотлыгып-йотлыгып, суны эчә башлаган. Эчкән саен күкрәгендә көч арта баруын сизгән. Бераздан инде бөтенләй сәламәтләнеп җиткән. Малай сөенә-сөенә урамга чыгып йөгергән.

«Белмәде, әнием суның кайсы чишмәнеке икәнлеген белмәде», — дип уйлаган ул. Шулай дип әйтүе булган, күктә яп-якты булып янучы кояш кинәт карала башлаган. Дөнья коточкыч ямьсезләнеп киткән. Кош-кортлар, куркышып, ояларына качканнар. Шомлы итеп, елап-елап, этләр өрергә тотынган. Малай, ни уйларга белмичә, курка-курка өенә чапкан.

— Әни, — дигән ул, сулышын көчкә-көчкә алып, — нишләптер кояшның йөзе каралды. Әнә тышка кара әле.

Әнисе кояшка караган да болай дигән:

— Кемдер бу дөньяда ялган эш кылган булырга тиеш, улым. Кояшның шул кеше өчен оялудан йөзе каралып чыккан. Чөнки җирдә кояш күрмәгән бер генә эш тә юк.

— Әни, — дигән малай, башын түбән иеп, — мин суны Көймә тавы артындагы чишмәдән алмаган идем, гафу ит мине.

Малай мөлдерәмә яшьле күзләре белән әнисенә караган. Әнисе улын күкрәгенә кыскан. Шул вакыт кояштагы караңгылык кими башлаган. Дөнья әкренләп яктырган, кошлар, кереп поскан ояларыннан чыгып, агач ботакларына кунганнар, этләр елый-елый өрүләреннән туктаганнар. Бар нәрсә элекке хәленә кайткан, бары тик кояштагы кара тап кына бөтенләй бетеп җитмәгән.

Әйе, дөньяда бер генә яманлык та, бер генә ялган да эзсез калмый шул. Яманлыкны хәтта кояш та яндырып бетерә алмый икән.

*Фәнис Яруллин*

# Сорауларга җавап бир

**1.** Әкият ничек башланып китә?
**2.** Авыру әнисе малайга нинди эш кушкан?
**3.** Малайның җавабы белән син килешәсеңме? Ә син ничек җавап бирер идең?
**4.** Әнисе суны Көймә тавы артындагы чишмәдән алып кайтырга куша. Аның суы тәмле дә, салкын да, шифалы да, ди. Син яши торган җирдә таулар, чишмәләр бармы? Исемнәре ничек?
**5.** Малай әлеге чишмәгә барганмы? Суны кайсы чишмәдән алган?
**6.** Алга таба әкият ничек дәвам итә?
**7.** Малай кабат урамга чыккач, дөнья нишләгән, сөйләп күрсәт.
**8.** Әнисе кояшның йөзе каралуын ничек аңлаткан? Димәк, әниләр — сизгер күңелле, акыллы кешеләр. Син бу фикер белән килешәсеңме? Ни өчен шулай уйлыйсың?
**9.** Малай үзенең хатасын аңлаганмы?
**10.** Малай гафу үтенгәч, дөнья әкренләп яктырган, бар нәрсә элекке хәленә кайткан, бары кояштагы кара тап кына бөтенләй бетеп җитмәгән. Ни өчен дип уйлыйсың?
**11.** Язучы Фәнис Яруллин моны ничек аңлата? Шул юлларны кабат укы һәм фикереңне әйт.
**12.** Чынлап та, дөньяда бер генә ялган да эзсез югалмый. Начар эш-гамәлләр үзеңә начарлык булып кайта. «Ялганчының өе янган, берәү дә ышанмаган», — диелә татар халык мәкалендә. Димәк, ялганчы кешенең бер сүзенә дә ышанмый башларга мөмкиннәр. Син мәкальдә әйтелгән фикер белән килешәсеңме? Ни өчен ялганчының өе януына берәү дә ышанмаган?
**13.** Әкиятне үзең дәвам итеп сөйләп кара. Сабак алган әлеге малай киләчәктә нинди кеше булыр дип уйлыйсың?

## Күпнокталар урынына сүзләр куеп әйт

Кояш кинәт *карала башлаган.*

* * *

Дөнья коточкыч *ямьсезләнеп киткән.*

* * *

Кош-кортлар ояларына *качканнар*.

* * *

Шомлы итеп, елап-елап, этләр өрергә *тотынган.*
Кояштагы каралык *кими башлаган.*

* * *

Дөнья әкренләп ... .

* * *

Кошлар, кереп поскан ояларыннан ... , агач ботакларына ... .

* * *

Этләр елый-елый өрүләреннән ... .

**Кайсы яктагы җөмләләр**
**әкиятнең ахыргы өлешенә туры килә?**

**Бал корты һәм Шөпшә**
*(Әкият)*

Чәчәкләр башлыгы бик зур ярыш үткәрергә булган. Шул турыда ул төрле якка хәбәр салган:

— Кем дә кем бал салырга яхшы савыт әзерли, ул савытта бал бер дә бозылмый, әчеми, барлык чәчәктәге балны шуңа бирәм! — дигән.

Бөҗәкләр көнне-төнне белмәгәннәр. Бар да тырышып савыт эшләгәннәр, бар да үзләре эшләгән савытларны Чәчәкләр башлыгына китергәннәр.

— Менә әйбәт савыт, балны кара салып! — дигәннәр.

Чәчәкләр башлыгы аларның барысын да борып җибәргән.

— Ашыккансыз, ашыккансыз, бик начар ясагансыз. Мондый савытлар миңа кирәкми. Шуңа күрә бал да сезгә эләкми! — дигән.

Шөпшә һәм Бал корты иң соңгылар булып эшкә керешкәннәр. Беренчелекне алырга өмет иткәннәр.

Бал корты көне буе бертуктамый эшли дә эшли икән. Ерак-ерак җирләргә очып бара, аллы-гөлле чәчәкләрдән бал суырып ала. Аны алып кайтып, үзе әзерләгән матур күзәнәкләргә сала икән.

Шөпшә дә чәчәкләрдән бал җыйган. Ләкин ул бик-бик ялкау булган. Иртән әзрәк кенә эшли дә, кояш кыздыра башлау белән, оясына кереп йоклый икән.

...Ярыш көне килеп җиткән.

Бал корты балавыздан эшләгән матур күзәнәкле бал савытын күтәреп очып киткән. Шөпшә үзенең аннан-моннан эшләгән кәрәзен алып килгән.

Чәчәкләр башлыгы кәрәзләргә бал салып караган. Шөпшә кәрәзендә бал тормаган. Ә Бал кортының кәрәзе акмаган, әйбәт булган.

— Тырышканнар, күп көч куйганнар, менә дигән кәрәз эшләп чыгарганнар. Шуңа күрә теләсә нинди чәчәктән теләсә никадәр бал җыярга бал кортларына рөхсәт бирәм! — дигән Чәчәкләр башлыгы.

Шул көннән башлап бал кортлары чәчәкләрдән бал ташый башлаганнар. Ә шөпшәләр ялкаулыклары аркасында хурлыкка калганнар.

*Абдулла Алиш*

## Сорауларга җавап бир

**1.** Чәчәкләр башлыгы нәрсә үткәрергә уйлаган?
**2.** Ул бу турыда нинди хәбәр әйткән?
**3.** *Әйткән* сүзен язучы Абдулла Алиш башкача ничек язган? Ә син тагын нинди сүз кулланыр идең?
**4.** Чәчәкләр башлыгы бөҗәкләр ясаган савытны ни өчен кире борган?
**5.** Бал корты белән Шөпшә ничек эшләгәннәр?
**6.** Шөпшә ясаган кәрәздә ни өчен бал тормаган, агып чыккан дип уйлыйсың?
**7.** Ә Бал кортының кәрәзе ни өчен акмаган?
**8.** Чәчәкләр башлыгы бал кортларының хезмәтен ничек бәяләгән?
**9.** Син бу мәкаль белән килешәсеңме? Ни өчен? Тырышлык һәм ялкаулык турында тагын нинди мәкаль-әйтемнәр беләсең?

## Мәкальләрне әйтеп бетер

*Тырышкан табар: ташка ... ... .*
*Эшсезгә көн дә ... .*
*Алма, пеш, авызыма ... .*
*Калган эшкә кар ... .*
*Эш эшләгән — интекмәс, эшләмәгән — ... ... .*

## Күпнокталар урынына сүзләр куеп әйт

— Кем дә кем бал салырга яхшы савыт әзерли, чәчәкләрдәге балны шуңа бирәм, — дигән ... ... .

... бар да тырышып савыт эшләгәннәр һәм Чәчәкләр башлыгына китергәннәр.

... аллы-гөлле чәчәкләрдән җыйган балларны үзе ясаган кәрәзләргә салган.

... , аннан-моннан эшләгән кәрәзен күтәреп, Чәчәкләр башлыгына килгән.

### Туган көндә

Бүген Фәридәнең туган көне. Әнисе, иртүк торып, бик матур торт пешерде. Өстәлгә төрле-төрле тәмле-татлы сый-хөрмәт тезде.

Өстендәге күлмәге дә бик матур бүген Фәридәнең. Анысын да әнисе тегеп кидерде аңа. Чәчләренә күлмәге төсле үк тасмадан күбәләкләр такты.

Өйләре дә искиткеч матур бүген аларның. Бөтен нәрсә ялт иткән! Бар да чиста, бар да пөхтә, бар да матур, бар да елмаеп-көлеп кенә торгандай күренә.

Фәридә куана-куана тирә-якка күз йөртеп чыкты. Күр инде, хәтта өстәлдәге чәчәкләргә кадәр елмая. Әле бүген генә алып кайткан, күрәсең, аларны әнисе!

Бар да шундый матур, шундый күңелле! Тиздән аның дус кызлары да килеп җитәр...

Фәридә әнисе янына аш бүлмәсенә керде.

— Әни, әни, дим, әйдә әби бүгенгә генә залга, минем кунакларым янына чыкмасын, ә? Югыйсә бүген анда бөтен нәрсә шундый матур, шундый яңа, ә әби шундый иске, әйем лә, шундый карт... бер дә килешми.

Әнисе башта аңышмыйчарак торды. Аннары, кинәт кенә хәлсезләнеп киткәндәй, кулларын салындырып урындыкка сеңде. Кулларын тезләренә куйган килеш байтак вакыт шулай сүзсез утырды ул. Аның йөзе бөтенләй үзгәргән, зур күзләре тирәнәеп, каралып киткәндәй булган иде.

— Менә нәрсә, Фәридә, дусларыңа шалтыратып әйт: бүген туган көнеңне уздырмыйбыз. Менә шулай, уздырмыйбыз... — диде ул.

*Резеда Вәлиева*

## Сорауларга җавап бир

**1.** Ни өчен Фәридәгә бөтен нәрсә матур, елмаеп-көлеп торгандай булып күренә?
**2.** Фәридәнең әнисе нәрсә пешерә?
**3.** Ә сезнең гаиләдә туган көн бәйрәмендә нинди ризыклар пешерәләр? Ризык пешергәндә, син әниеңә ярдәм итәсеңме?
**4.** Фәридә ничек итеп киенгән? Ул матур күлмәкне аңа кем теккән?
**5.** Фәридә әнисенә:
— ... әби бүгенгә генә залга, минем кунакларым янына чыкмасын. Ул шундый иске, әйем лә, шундый карт... бер дә килешми, — ди.
Әнисе кызының бу сүзләрен ничек кабул итә? Язучы Резеда Вәлиева әни кешенең бу халәтен, кичерешләрен ничек тасвирлый, сөйләп күрсәт.
**6.** Ни өчен әнисе Фәридәгә:
— ... дусларыңа шалтыратып әйт: бүген туган көнеңне уздырмыйбыз... — ди.
Ә син нәрсә дип җавап бирер идең?
**7.** Кызның сүзе белән син килешәсеңме? Чынлап та, әби кеше табынны ямьсезлиме, аңлатып бир.
**8.** Хикәягә башка исем куй.
**9.** Хикәяне үзең дәвам итеп сөйләп кара.

# Дәү әнием

Әниемнең әнисе
Әбием була минем.
Әби генә түгел әле,
Ул минем дәү әнием.

Ак ефәктәй чәчләрен
Ул тарап куя үреп.
Чисталыкка өйрәнәм
Мин дә аңардан күреп.

Тәмле ашлар пешерә,
Матур гөлләр үстерә.
Өебезнең нуры ул,
Барыбыздан олы ул.

Кызыклы әкиятләр
Сөйли кичләрен безгә.
— Бәбкәм, — диеп, иркәләп
Эндәшә үзе безгә.

Җылы оек, бияләй
Бәйли безгә, көз җиткәч.
Мин дә аңа бүләкләр

Алырмын үсеп җиткәч.

*Әминә Бикчәнтәева*

Язучы Әминә Бикчәнтәева дәү әнисен шулай тасвирлый. Ә синең дәү әниең әкиятләр сөйлиме? Нинди әкиятләр сөйли? Син аны ничек сөендерәсең? Ул сезнең гаиләдә нинди урын тота?

Фәридәнең фикере дөрес булмавын тагын бер кат аңлат. «Өлкәннәрне яратмаганның үзен дә яратмаслар» мәкале белән син килешәсеңме? Ни өчен?

## Өч кыз

*(Татар халык әкияте)*

Борын-борын заманда булган икән, ди, бер хатын. Аның булган, ди, өч кызы. Бу хатын, кызларымның өсте бөтен, тамаклары тук булсын, ди-ди, көне-төне эшләгән, ди.

Менә кызлар үсеп буйга да җиткәннәр. Алар берсеннән-берсе матур, ди, бер битләре ай, бер битләре кояш, буй-сыннары карлыгачтай сылу, ди. Өч кыз, бер-бер артлы кияүгә чыгып, берсе артыннан берсе китеп тә барганнар.

Менә бер ел үткән, ике ел, өч ел үткән. Шулай матур гына яшәгәндә, әниләре авырып киткән. Күрше урамда Тиен дусты бар икән, хатын шуны дәшеп әйткән:

— Тиен дустым, барсана, кызларыма әйтсәнә, хәлемне белергә килсеннәрче, — дигән.

Тиен шунда ук чыгып чапкан. Тиен барып тәрәзә какканда, олы кыз җиз ләгәннәр чистартып тора икән.

— Һай, — дип әйткән, ди, олы кыз, — бик барыр идем дә бит, аңарчы менә шушы ләгәннәрне чистартып бетерәсем бар иде шул, — дигән, ди.

Тиен моңар бик ачуланган да әйткән:

— Алайса, син шушы ләгәннәреңнән мәңгегә аерылма! — дигән.

Тиеннең шулай дип әйтүе булган, ике ләгән кызны ике яктан күтәреп тә кысканнар. Олы кыз егылган да шунда ук бакага әверелгән.

Тиен уртанчы кызга чапкан. Уртанчы кыз, бу кайгылы хәбәрне ишеткәндә, киндер суга икән. Тиенгә әйткән:

— Һай, — дигән, — әнием янына хәзер үк чыгып йөгерер идем дә бит, менә ярминкәгә киндер сугып өлгертәсем бар иде шул, — дигән.

Тиен бик ачуланган да әйткән:

— Алайса, син гомерең буе киндер сугып кына яшә! — дигән.

Уртанчы кыз шунда ук үрмәкүчкә әверелгән.

Тиен тәрәзәсен какканда, кече кызның камыр баскан чагы икән. Ул бер сүз дә әйтмәгән, камырлы кулларын да сөртеп тормаган, чыккан да әнисе янына йөгергән.

Тиен кече кызга әйткән:

— И сөекле бала, гомер буе игелек күр, кешеләрне бәхетле ит, аларга куаныч та, юаныч та бул. Кешеләр дә сине сөярләр, синең яхшылыгыңны мәңге онытмаслар, — дигән.

Кече кыз чыннан да бик рәхәт гомер кичергән, халык аны бик яраткан, ди.

## Сорауларга җавап бир

**1.** Әкият ничек башланып китә?

**2.** Кызларның матурлыгы әкияттә ничек тасвирлана? Битләре нәрсә белән чагыштырыла? Буй-сыннары нәрсә белән тиңләштерелә?

**3.** Кызларның әниләре нишләгән?

**4.** Ул кемне чакырган? *Кем?* соравы татар телендә кешеләргә генә куела. Бу очракта Тиенгә ни өчен *кем?* соравы куела?

**5.** Тиен башта кайсы кыз янына барган?

**6.** Кыз ни өчен әнисе янына бармаган?

**7.** Тиен аны нәрсәгә әверелдергән?

**8.** Уртанчы кыз янына баргач, нинди хәлләр булган?

**9.** Кече кызның нишләгән вакыты булган?

**10.** Ул Тиеннең сүзен тыңлаганмы?

**11.** Тиен аңа нинди теләк теләгән?

**12.** Аның бу теләге кабул булганмы?

Кыз ничек гомер кичергән?

**13.** Син бу сүзләр белән килешәсеңме? Кече кызга бәйләп, фикереңне нигезлә.

## Эчтәлек


Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар *(А.Алиш)* ..... 4

Ай белән Кояш *(Татар халык әкияте)* ..... 16

Ак песи *(Г.Мөхәммәтшин)* ..... 24

Бүләк кемгә? *(Татар халык әкияте)* ..... 32

Кояштагы тап *(Ф.Яруллин)* ..... 40

Бал корты һәм Шөпшә *(А.Алиш)* ..... 48

Туган көндә *(Р.Вәлиева)* ..... 58

Өч кыз *(Татар халык әкияте)* ..... 64



Литературно-художественное издание

Для чтения взрослыми детям

**Серия «Здравствуй, школа!»**

# Пчела и Оса

Казань. Татарское книжное издательство. 2008

На татарском языке

**«Исәнме, мәктәп!» сериясе**

# Бал корты һәм Шөпшә

Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*. Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Ф.Р.Гыйсмәтуллина*. Корректоры *Р.Н.Шакирова*. Оригинал-макеттан басарга кул куелды 15.08.2008. Форматы 60x84 $^{1}/_{16}$. Шартлы басма табагы 4,19 + форз. 0,23. Шартлы буяу-оттиск 18,14. Нәшер-хисап табагы 3,12 + форз. 0,39. Тиражы 5000 д. Заказ Т-1007. Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19. http://tatkniga.ru. E-mail: tki@tatkniga.ru.
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ. 420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.